**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча кайбер указларына үзгәрешләр кертү турында

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләренә кагылышлы федераль законнарга үзгәрешләр кертелү сәбәпле, шулай ук «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-37 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-987 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «з$^{1}$» пунктчасын өстәргә:

« з$^{1}$) Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру өчен махсуслаштырылган мәгълүмати ресурс (dohod.tatar.ru) буенча Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфалар (алга таба – муниципаль вазыйфалар) (аларны биләү муниципаль сайлаулар йомгаклары буенча башкарыла торган муниципаль вазыйфа биләүне дәгъвалаучылар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү белән бәйле

очраклардан кала) яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын, биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне кабул итүне башкару;»;

«и» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;»;

б) 6 пунктның тугызынчы абзацына «, шулай ук, персональ мәгълүматларны саклауга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен тәэмин итеп, үз компетенцияләре чикләрендә «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан.».

2. «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы һәм 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның «а» пунктчасында:

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацка «, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлардан тыш;» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «икенче - бишенче абзацларда» сүзләрен «икенче, өченче һәм бишенче абзацларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты түбәндәгеләрнең чыгымнарын контрольгә алу турында карар кабул итә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасын биләүче затның;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның;

Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфалар (алга таба – муниципаль вазыйфалар) биләүче затларның;

контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның;

әлеге пунктның икенче-бишенче абзацларында күрсәтелгән затларның хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балаларының.»;

в) 5 пунктның «б» пунктчасында «1 пунктның «а» пунктчасында өченче - бишенче абзацларда» сүзләрен «1 пунктның «а» пунктчасында өченче һәм бишенче абзацларда» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктта «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон» сүзләреннән соң «, Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» дигән сүзләрне өстәргә;

д) 9 пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Указның дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән затларның, шулай ук аларның хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балаларының;»;

е) 10 пунктта «1 пунктның «а» пунктчасында дүртенче һәм бишенче абзацларында» сүзләрен «1 пунктның «а» пунктчасында бишенче абзацта» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Федераль дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы» сүзләреннән соң «, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль

вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә:

1 пунктта:

«а» пунктчасында («алга таба – гражданнар)» сүзләреннән соң «, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасыннан кала» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «(алга таба– муниципаль хезмәткәрләр)» сүзләреннән соң «, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасыннан кала» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы һәм 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пунктын өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турында нигезләмәне ($3^1$ нче кушымта) расларга.»;

б) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында нигезләмәдә:

6 пунктка «$д^1$» пунктчасын өстәргә:

«$д^1$) муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруга кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерә;»;

15 пунктта «6 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «6 пунктның «д» һәм «$д^1$» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның 13 октябрендәге
ПУ-986 номерлы Указына
3[1] нче кушымта

**Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан түбәндәгеләрне карап тикшерү тәртибе билгеләнә:

а) муниципаль вазыйфаларны (алга таба – муниципаль вазыйфалар), контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү йомгакларын;

б) муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшырылмавына яисә хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкин булмавы хакында аның гаризасына кагылышлы мәсьәләләрне.

2. Комиссия утырышын уздыруга нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) Комиссия рәисенең түбәндәгеләргә нигезләнеп кабул иткән карары:

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан уздырылган тикшерүнең Комиссиягә тапшырылган материаллары;

Комиссиягә карап тикшерү өчен кертелгән, муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан коррупциягә каршы көрәшү өлкәсенә караган законнар таләпләре бозылу турындагы башка материаллар;

б) муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче заттан хатыны (ире) һәм балигъ булмаган

балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкин булмавы хакында Татарстан Республикасы Президентына бирелгән гаризасы.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне бирү өчен билгеләнгән вакытта бирелә.

Идарәдә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза беренчел карап тикшерелә һәм аның йомгаклары буенча дәлилле бәяләмә әзерләнә.

4. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында каралган дәлилле бәяләмә әзерләгәндә Идарәнең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча билгеләнгән тәртиптә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә гариза биргән затлардан тиешле аңлатмалар алырга хокуклы, ә Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга соратулар җибәрергә мөмкин.

Гариза, бәяләмә һәм башка материаллар гариза алынганнан соң җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла.

Соратулар җибәргән очракта, гариза, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә гариза алынган көннән 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге вакыт озайтыла да ала, әмма бу озайту 30 көннән дә артып китә алмый.

5. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризада һәм аның йомгаклары буенча әзерләнгән дәлилле бәяләмәдә муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тапшырмавы сәбәбе объектив һәм нигезле дигән нәтиҗә ясау өчен җирлек булганда, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең 18 пунктының «а» пунктчасында карлаган карар кабул итәргә мөмкин.

6. Бәяләмә һәм аңа нигезләнеп кабул ителгән карар Комиссия әгъзаларына мәгълүмат буларак Комиссиянең якын арада булачак утырышында игълан ителә. Гариза биргән затка кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат язма рәвештә җиде эш көне дәвамында җиткерелергә тиеш.

7. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр карап тикшереләчәк Комиссия утырышын уздыру датасын һәм аны уздыру вакытын Комиссия рәисе билгели.

8. Комиссия секретаре Комиссия утырышында каралачак мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә, шулай ук Комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр,

утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында утырышка кимендә өч эш көне кала хәбәр итә.

9. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

10. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокуклы була.

11. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының берсенә кагылышлы мәсьәлә каралса, тиешле карар кабул иткәндә, әлеге Комиссия әгъзасының тавыш бирергә хокукы булмый.

12. Комиссия утырышы гадәттә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә гариза биргән зат катнашында уздырыла. Гариза биргән зат утырышта шәхсән катнашырга нияте булуы турында гаризасында күрсәтә.

13. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә гариза биргән заттан башка гына Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда уздырыла:

а) әгәр гаризада аны биргән затның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте турында белдерелмәгән булса;

б) әгәр дә Комиссия утырышында катнашырга нияте булган һәм утырышны уздыру вакыты һәм урыны турында аңа тиешенчә хәбәр ителгән гариза биргән зат Комиссия утырышына килмәсә;

14. Комиссия утырышына Комиссия рәисе карары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, шулай ук кызыксынган органнар һәм оешмалар вазыйфаи затлары чакырылырга мөмкин.

15. Комиссия утырышында Комиссия рәисе билгели торган тәртиптә муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның аңлатмалары тыңлана һәм утырыш көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карап тикшерелә. Комиссия утырышында Комиссия әгъзалары, муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат соравы белән башка затлар күрсәтмәләре тыңланырга һәм алар тәкъдим иткән материаллар карап тикшерелергә мөмкин.

16. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашкан затларның аларга Комиссия утырышы вакытында мәгълүм булган белешмәләрне таратырга хакы юк.

17. Материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «а» пунктчасында каралган Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә ала:

а) карап тикшерелә торган очракта муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан вазыйфаи (хезмәт урынында) тәртип таләпләрен бозу билгеләре юк, дип билгеләргә;

б) карап тикшерелә торган очракта муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат

тарафыннан вазыйфаи (хезмәт урынында) тәртип таләпләрен бозу билгеләре бар, дип билгеләргә;

18. Материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында каралган Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә ала:

а) муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшырмавы сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

б) муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшырмавы сәбәбен объектив түгел һәм нигезсез дип танырга. Бу очракта Комиссия муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка әлеге белешмәләрне тапшыру чараларын күрүне тәкъдим итә;

в) муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшырмавы сәбәбен объектив түгел һәм әлеге белешмәләрне тапшырудан читләшү булып тора дип танырга.

19. Комиссия тарафыннан муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның административ хокук бозу буларак сыйфатланырдай билгеләре яисә җинаять составы булган гамәлләр кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланганда, Комиссия секретаре Комиссия рәисе йөкләве буенча әлеге гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны өч көн вакыт эчендә, ә кирәксә – кичекмәстән хокук саклау органнарына җибәрә.

20. Комиссиянең карарлары коллегиаль рәвештә аның утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

21. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларга Комиссия рәисе һәм секретаре кул куя.

22. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында каралган гаризада аны биргән затның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте барлыгы турында күрсәтелмәгән очракта, Комиссия рәисе карары белән әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирү Комиссия әгъзаларына сораулар язылган кәгазь битләре, шулай ук башка материаллар җибәрү юлы белән читтән торып уздырылырга мөмкин.

Сораулар язылган кәгазь битләрен тутырганда Комиссия әгъзасы Комиссия тәкъдим иткән карарга карата үз фикерен, аны яклап яисә аңа

каршы тавыш биреп, ачык итеп белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы кул куйган сораулар язылган кәгазь битләре аны алган көннән өч көннән дә соңга калмыйча, Комиссиягә юллана.

Комиссиянең читтән торып тавыш бирү йомгаклары буенча кабул ителгән карары әлеге Нигезләмәнең 23 пункты таләпләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куелган көннән җиде эш көне дәвамында Комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга җибәрелә.

23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашкан башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре күрсәтелә;

б) Комиссия утырышында каралучы, мәсьәләләрнең һәрберсенең аңа кагылышлы мәсьәлә тикшерелгән муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелгән формулировкасы;

в) Комиссия утырышын уздыруга нигез булган сәбәп күрсәтелгән мәгълүмат чыганагы һәм аның Идарәгә кергән датасы;

г) муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның һәм башка затларның тикшерелә торган мәсьәләләр асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме һәм аталары исеме һәм чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) Комиссия карары һәм аны кабул итүне нигезләү.

24. Кабул ителгән карардан риза булмаган Комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язмача бирергә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

25. Комиссия карарының күчермәсе аңа кагылышлы мәсьәлә тикшерелгән муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка, шулай ук аны вазыйфага билгеләү (сайлау, раслау) вәкаләте булган Татарстан Республикасында җирле үзидарә органына Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куйган көннән биш эш көне эчендә юллана.

26. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

__________».

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 02 декабрь
№ ПУ-1042

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН